Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге
Юныс торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

24 ноябрь, 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлегенең Юныс торак пунктында 2019 елның 24 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 47 (кырык җиде).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 25 (егерме биш).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 25 (егерме биш)

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «2020 елда Пимәр авыл җирлегенең Юныс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, көндезге уку формасындагы студентларынан тыш, бер тапкыр түләүләреннән азат итү һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов